КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 13 ноябрь г.Казань № 992

Спас муниципаль районында җир кишәрлекләрен бер категориядән икенче категориягә күчерү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Спас муниципаль районы башкарма комитетының Спас муниципаль районында урнашкан, дәүләт милкендә булган 16,3116 гектар гомуми мәйданлы авыл хуҗалыгы әһәмиятендәге җир кишәрлекләрен түбәндәге кадастр саннары белән Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан күчермәләрдә күрсәтелгән чикләрдә ритуаль эшчәнлек объектларын урнаштыру максатларында сәнәгать җирләре һәм башка махсус әһәмияттәге җирләр категориясенә күчерү турындагы тәкъдимен кабул итәргә:

| Җир кишәрлегенең кадастр саны | Мәйданы, гектар |
|---|---|
| 16:37:040602:108 | 0,881 |
| 16:37:050501:67 | 1,3536 |
| 16:37:060602:132 | 1,1899 |
| 16:37:060602:133 | 0,224 |
| 16:37:070501:94 | 0,7603 |
| 16:37:070402:61 | 0,7973 |
| 16:37:091001:64 | 1,3653 |
| 16:37:110501:76 | 1,1137 |
| 16:37:110501:77 | 1,4442 |
| 16:37:110701:103 | 0,7518 |
| 16:37:130401:38 | 2,0506 |
| 16:37:130702:4 | 3,26 |
| 16:37:140401:152 | 1,1199 |
| Барлыгы | 16,3116. |

2. Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрына билгеләнгән тәртиптә тиешле үзгәрешләр кертүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин